**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
МӘЛӘКӘС АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ**

**КАРАР**

03 октябрь, 2022 ел | Мәләкәс авылы | № 15

«Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Мәләкәс авыл җирлеге Калинин авылында үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында»

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Тукай муниципаль районының «Мәләкәс авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының

**КАРАР БИРӘМ:**

1. 2022 елның 08 октябренә 15:00 сәгаттә Тукай муниципаль районы Мәләкәс авыл җирлеге Калинин авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләргә.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«2023 елда яшәү урыны буенча Мәләкәс авыл җирлеге Калинин авылында территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешегә 1000 (бер мең) сум күләмендә бер тапкыр түләү кертергә һәм I, II төркем инвалидлары һәм Бөек Ватан сугышы ветераннары, ялгыз яшәүче өлкән яшьтәге гражданнар һәм көндезге формада укучы студентлар, күп балалы гаиләләр өчен бер тапкыр түләү күләмен киметергә һәм аны әлеге категория гражданнар өчен 500 (биш йөз) сум күләмендә билгеләргә, әлеге сумманы түбәндәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерергә Сез ризамы:

- юлларны ремонтлау;
- урамнары яктырту;
- территорияне төзекләндерү (төрле функциональ билгеләнештәге мәйданчыклар, кече архитектура формаларын урнаштыру, конструктив җайланмалар, куркынычсызкнытәмин итү буенча чаралар комплексы);
- янгын сүндерү машинасы өчен гаражны төзекләндерү (төзелеш материаллары, җиһаз сатып алу)

«ӘЙЕ» «ЮК».

3. Гражданнар җыенын түбәндәге адрес буенча үткәрергә: Татарстан Республикасы, Тукай районы, Калинин авылы, Үзәк урам, 17Б.

4. Халык җыенын оештыручы итеп Тукай муниципаль районы Мәләкәс авыл җирлеге Башкарма комитетын билгеләргә.

5. Әлеге карарны авыл җирлегенең рәсми стендларында урнаштырып, халыкка игълан итәргә.

6. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районының рәсми сайтында «авыл җирлекләре» бүлегендә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында урнаштырырга.

7. Әлеге карар халыкка игълан ителгән көннән үз көченә керә.

Мәләкәс авыл җирлеге Башлыгы Ю.П.Васильев